| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**06.10.2020** | г. Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1914** |

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 17.04.2020 ел, 17 апрель, 678 нче карары белән расланган, гражданнарның аерым категорияләрен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле исемле бердәм электрон социаль йөртү билетлары буенча йөртүдән алынмаган керемнәрне каплау максатларында, оешмаларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү турында гаризаларны карау комиссиясе хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләргә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшмәкәрләргә, шулай ук товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр житештерүчеләргә физик затларга субсидия бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга гомуми таләпләр турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 сентябрендәге 887 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 17 апрелендәге 678 нче карары белән расланган, гражданнарның аерым категорияләрен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле исемле бердәм электрон социаль йөртү билетлары буенча йөртүдән алынмаган керемнәрне каплау

максатларында, оешмаларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү турында гаризаларны карау комиссиясе (алга таба-Комиссия) хакындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү һәм аны әлеге карарның кушымтасы нигезендәге редакциядә бәян итәргә.

2. 2020 елның 17 апрелендәге « Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан, аерым категориядәге гражданнарны исемле электрон бердәм социаль юлда йөрү билеты буенча ташудан җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итүгә бәйле алынмаган керемнәрне каплау максатларында, оешмаларга субсидияләр бирү турындагы гаризаларны карау буенча комиссия төзү турындагы» 678 номерлы карарына 2 нче кушымтаны үз көчен дип санарга.

3. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны интернет челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы А. В. Старостин

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
кушымта
06.10.2020 №1914

**Гражданнарның аерым категорияләрен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле исемле бердәм электрон социаль йөртү билетлары буенча йөртүдән алынмаган керемнәрне каплау максатларында, оешмаларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү турында гаризаларны карау комиссиясе турында**

# НИГЕЗЛӘМӘ

1. Комиссия субсидияләр бирү турындагы гаризаларны һәм аларга кушып бирелә торган документларны карауны гамәлгә ашыра.

2. Комиссиянең персональ составы Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән раслана. Комиссия әгъзалары саны-5.

3. Комиссия үз эшчәнлеген Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары нигезендә туктата.

4. Комиссия составына рәис, комиссия әгъзалары һәм секретарь.керә.

4.1. Комиссия рәисе:

- Комиссия утырышын үткәрү урынын һәм вакытын билгели;
- Комиссия утырышын алып бара;
- Комиссия әгъзалары тарафыннан документларны карап тикшергәннән соң, тапшырылган документларны, исәп-хисапларны карый;
– тапшырылган документларның « Гражданнарның аерым категорияләрен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле исемле бердәм электрон социаль йөртү билетлары буенча йөртүдән алынмаган керемнәрне каплау максатларында, оешмаларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү турында гаризаларны карау комиссиясе турында нигезләмә» (алга таба- «Субсидия турында нигезләмә») таләпләренә туры килү-килмәве турындагы бәяләмәгә кул куя;
- Комиссия утырышы беркетмәсенә кул куя.

4.2. Җаваплы секретарь:

- субсидия алуга дәгъва кылучыларның гаризалары реестрын алып бара;
- чираттагы утырышның көн тәртибе проектын төзи;
- Комиссия утырышы үткәрү урыны һәм вакыты турында Комиссия әгъзаларына хәбәр итә;
- Комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;
- Комиссия әгъзалары белән берлектә бирелгән документларны, субсидия алуга дәгъва итүчеләрнең хисапларын карап тикшерә;
- тапшырылган документларның «Субсидияләр турындагы нигезләмә »таләпләренә туры килүе яки туры килмәве турындагы бәяләмәгә кул куя;

-субсидияләр алуга дәгъва итүчеләр тарафыннан бирелгән документларның һәм хисапларның туры килүе яки туры килмәве турында бәяләмә әзерли.

4.3. Комиссия әгъзалары:

- субсидия алуга дәгъва итүчеләрнең бирелгән документларын, хисапларын карауны гамәлгә ашыралар;

- тапшырылган документларның «Субсидияләр турындагы нигезләмә» таләпләренә туры килүе яки туры килмәве турындагы бәяләмәне имзалый

- утырышның көн тәртибенә куелган мәсьәләләр буенча тавыш бирүдә катнаша.

5. Комиссия тапшырылган документларны карый һәм тапшырылган документларның Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 10.04.2020 ел, №641 карары белән расланган, гражданнарның аерым категорияләрен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез файдалануны тәэмин итүгә бәйле исемле бердәм электрон социаль йөртү билетлары буенча йөртүдән алынмаган керемнәрне каплау максатларында, оешмаларга Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү турында гаризаларны карау комиссиясе турында нигезләмә таләпләренә туры килү – килмәү турындагы (алга таба-Нигезләмә), әлеге документлар кергәннән соң, 5 (биш) эш көне эчендә, бәяләмәне әзерли.

6. Комиссия утырышы, әгәр анда 3 (өч) һәм аннан күбрәк әгъзасы катнашса, хокуклы дип санала. Комиссия утырышларында Комиссия әгъзалары алмаштыру хокукыннан башка катнаша. Утырышта Комиссия әгъзасы булмаганда, карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерләрен, язма рәвештә бирергә хокуклы.

6.1. Карар комиссия әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда Комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

6.2. Комиссия карарлары, Комиссия утырышында катнашкан йә үз фикерен язма рәвештә юллаган, Комиссия рәисе һәм әгъзалары имзалый торган бәяләмә белән рәсмиләштерелә. Бәяләмәне Комиссия секретаре 2 көн эчендә рәсмиләштерә.

7. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты карары, гариза бирүчегә субсидия бирү яисә субсидия бирүдән баш тарту турында мөрәҗәгать итүчегә, аның басылып чыккан көненнән 3 (өч) эш көне эчендә, җибәрелә. Субсидия бирүдән баш тарту турындагы карар мотивлаштырылган булырга тиеш (Нигезләмә нигезендә).

8. Агымдагы елның декабренә бирелгән субсидия әлеге ай өчен алучыга туры килә торган субсидиядән артса (бирелгән хисаплар нигезендә), артык суммасы, агымдагы елның 25 гыйнварына кадәр, агымдагы елның 25 гыйнварына кадәр ЗМР бюджетына кире кайтарылырга тиеш. Комиссия тарафыннан әлеге фактны тикшергәндә һәм әлеге шартны бозу очрагын ачыклаганда, Комиссия , 2 көн эчендә, субсидияне кире кайтару срокларын бозу турында акт төзи һәм имзаланган акт субсидия алучыга җибәрелә .